**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел .: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

2025 елның «21» июленнән | № 160

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2024 елның 08 ноябрендәге 278 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча белем алучыларны тукландыруны тәэмин итү бәясенә үзгәреш кертү турында» 2025 елның 27 маендагы 362 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2024 елның 08 ноябрендәге 278 номерлы карарына (2024 елның 27 ноябрендәге 297 номерлы, 2025 елның 25 февралендәге 48 номерлы карарлардагы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 1.2 пунктчасында «9 сум 60 тиен» сүзләрен «10 сум 30 тиен» сүзләренә алмаштырырга, шул исәптән җирле бюджет акчалары исәбеннән субсидияләрне исәпкә алып.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда:

https://pravo.tatarstan.ru , «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https:/ novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Е.А. Тарнавский